Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«11» ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Яңа Иглай авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Яңа Иглай авыл җирлегендә яшәүче 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән кала 2023 елда балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү максатында суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау һәм төзү-монтаж эшләре өчен кирәкле товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Яңа Иглай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- Яңа Иглай авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Яңа Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- Яңа Иглай авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Р. Рәхмәтуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Рәхмәтуллин